**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Починок Кучук авыл җирлеге башлыгы урынбасары**
**КАРАРЫ**

**2024 елның 31 октябре** **№ 3**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Чигайка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 14 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Чигайка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар жыенын түбәндәге адрес буенча шәхси йортта үткәрергә: Чигайка авылы, Совет ур., 12.

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Чигайка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган

инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су суырту манарасын, су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (коеларны ремонтлау һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Чигайка авылы чишмәләрен һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү, төзү һәм карап тоту, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр),

(зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре),

(массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары, хезмәт күрсәтү өчен техника сатып алу) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Чигайка авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Починок Кучук авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Починок-Кучук
авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Г.И. Петров